# ТУГАН ТЕЛ ПРЕДМЕТЫ БУЕНЧА УКУЧЫЛАРДАН КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

## Укытуның шәхси нәтиҗәләре

- укучыларда күпмилләтле җирлектә яшәүче халыкларга карата ихтирамлык, гражданлык бердәйлеге хисләре формалаштыру;
- *туган җир, Ватан* төшенчәләре, үз культураң аша дөнья культурасына карата ихтирам тәрбияләү, аны өйрәнү теләге формалаштыру;
- үзлегеңнең белемеңне арттыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү нигезендә, үз эшчәнлегеңне оештыра алу осталыгын формалаштыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү.

## Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

Төп белем бирү баскычында татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга хезмәт итә.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм төзи белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгели белү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллана белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләр формалашу;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзи белү;
- аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре формалашу;
- парларда һәм күмәк эшли белү.

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда туган телнең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятκә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Туган телгә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– Укучыларның коммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, туган телдә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;
– «Туган теле» предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында туган телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**5 нче класс**

Туган тел дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:
-Тартым һәм килеш белән төрләнгән ялгызлык һәм уртаклык исемнәрнең берлек һәм күплек сан кушымчаларын аера белергә.
-Тамыр, кушма, парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларның сөйләмдә кулланырга. -Татар телендә аффиксларның кушылу тәртибе белән танышырга.
-Сыйфат дәрәҗәләре белән таныштырга, аларны сөйләмдә кулланырга. -Микъдар,тәртип, җыю саннарын аера белергә.
-Мин, син, ул зат алмашлыкларын иялек, төшем, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә куллана белергә.
-Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен сөйләмдә кулланырга.
-Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен сөйләмдә кулланырга.
-Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-санда төрләнеше белән танышырга.
-Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнешен сөйләмдә кулланырга.
-Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә кулланырга.
- Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (кирәк, кирәкми, ярый, ярамый) белән сөйләмдә кулланырга.
-Эшләргә телим төзелмәсен сөйләмдә кулланырга.
-Өчен, шикелле бәйлекләрен сөйләмдә кулланырга.
-Минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, минем фикеремчә кереш сүзләрен сөйләмдә кулланырга.
-Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-санда төрләнеше белән танышырга.
–лык /-лек, -даш / -дәш, -таш / -тәш исем ясагыч кушымчалары белән танышырга. -Җөмләдә ия белән хрне дөрес куллана белергә өйрәнергә.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерүгә мөмкинлек бирелә:

- сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белергә.
- терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белергә;
- татар сөйләм үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә корырга, сөйләшә белергә.
- программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белергә;
- конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белергә;
- монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белергә;
- өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белергә.

**6 нчы сыйныф**

Туган тел дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:

-Тартымлы исемнәрне килешләрдә төрләндерергә, текстта таный белергә
-Транскрипция билгеләрен аера белергә
-Иялек килеше, сораулары, кушымчаларын өйрәнергә
-Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы, кушымчаларын белергә
-*3 нче зат берлек сан хәзерге заман х.ф. + беләм* төзелмәсен, *боерык фигыль + әле* төзелмәсен сөйләмдә кулланырга
-Шарт фигыль. Шарт фигыльнең юклык формасы. Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, сөйләмдә кулланырга
-Сыйфат дәрәҗәләрен, предметларда дәрәҗә билгеләрен дөрес кулланырга -Теләк белдерү формасы: *инфинитив + телим* төзелмәсен куллана белергә
-Үтенеч һәм рөхсәт сорау формалары: *барыйм инде, барыйм әле* төзелмәләрен кулллана белергә
-Теләк белдерү формасы: *эчәсе килә төзелмәсен* куллана белергә
-Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше белән танышырга
-Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше белән танышырга -*Чөнки, шуңа күрә* теркәгечләрен сөйләмдә кулланырга. -*Аркылы* бәйлеген сөйләмдә кулланырга
-*Идел Чулманнан зуррак* төзелмәсен, *Казаннан Яр Чаллыга* кадәр төзелмәсен сөйләмдә кулланырга.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерүгә мөмкинлек бирелә:

-татар теленең башка телләр арасындагы урынын белергә;
-татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазлы сүзлзрне дөрес әйтә белергә;
-авазларны сүзләрдә, сүтезмәләрдә, җөмләләрдә дөрес әйтүгә ирешү һәм сингармонизм законының асылына төшенергә;
-сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештыра белергә;
-телара, антонимнар, синонимнар һәм башка төр сүзлекләрдән файдалана белергә;
-татар әдәби теленең, орфоэпик,орфографик, лексик, грамматик, пунктуацион нормаларына нигезләнеп һәм татар җөмләсендә сүз тәртибе үзенчәлекләрен белеп, телдән яки язма сөйләм оештыруга ;
-коммуникатив максатларны аңлап, диалогик аралашуда катнаша һәм үз фикерләрен эзлекле итеп белдерә алуга;
-төрле аралашу сфераларыннан чыгып, телдән яки язмача үз фикерләрен белдерүгә.

**7 нче класс**

Туган тел дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:
-Ясалышы буенча сыйфат төрләре.
-Рәвеш төркемчәләре.
-Теләк фигыльнең 1нче зат берлек һәм күплек сан формалары.

-Сыйфат фигыльнең хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.
-Хәл фигыль белән таныштыру.
-Исем фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.
-Җыючы (һәм, да-да, та-та,ни...ни), каршы куючы (ләкин, ә, әмма), бүлүче (я, яки) теркәгечләре белән җөмләләр төзү күнекмәләрен системалаштыру. -Ияртүче (әгәр, шуңа күрә) теркәгечләрне сөйләмдә куллану.
-Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.
-Җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, алар арасында сызык куелу очраклары белән таныштыру.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерүгә мөмкинлек бирелә:
-Яңа уку елындагы яңалыклар, җәйге ялны ничек уздыру, классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләргә. Начар билгегә үз карашын әйтергә, уку-язу әсбапларын тәртиптә тотарга, яхшы уку серләре, яхшы уку өчен нинди холык сыйфатлары кирәклеге турында сөйләргә.
-Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү турында, яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы турында сөйләргә.
-Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте, кушкан эшкә җаваплы карау турында сөйләргә. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне, кайчан кайтасыңны әйтә белергә, өлкәннәрдән рөхсәт сорый белергә. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү, әти-әниләрне бәйрәм белән котлау турында сөйли белергә.
-Татарстанның табигате, аның табигый байлыклары турында сөйли белергә. Туган як табигатенә карата үз фикереңне белдерә белергә.Татарстанның территориясе, аның географик урыны. Атаклы композитор Сара Садыйкова турында мәгълүмат алырга.

**8 нче класс**

Туган тел дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:

- Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен таба һәм аера белү күнекмәләрен үстерергә.
-Кушма исем һәм кушма фигыль хәбәрле җөмләләрне дөрес аңларга һәм рус теленә тәрҗемә итәргә.
-Сыйфат фигыльнең заман формаларын сөйләмдә дөрес кулланырга.
-Хәл фигыльнең төрләрен гамәли үзләштерү эшен дәвам итү.
-Өйрәнелгән затланышлы һәм затланышсыз фигыльләрнең морфологик формаларын кабатлау.
-Аналитик фигыльләрнең мәгънә төсмерләрен аңлап кулланырга һәм рус теленә тәрҗемә итәргә өйрәтү.
-Фигыльнең төшем һәм йөкләтү юнәлешләре белән таныштыру.
-Бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең төркемчәләрен сөйләмдә һәм язуда куллану күнекмәләрен тирәнәйтү.
-Тәрҗемәле, омонимнар, антонимнар, синонимнар, фразеологик һәм башка төр сүзлекләрдән файдаланырга күнектерү.
-Сөйләмдәге актив ымлыклар һәм аваз ияртемнәре белән таныштыру.
-Бер составлы фигыль җөмләнең актив кулланыштагы төрләрен гамәли үзләштерү (билгеле үтәүчеле, билгесез үтәүчеле, гомуми үтәүчеле, үтәүчесез җөмләләр).
-Атау җөмләләрне танып белергә һәм сөйләмдә кулланырга күнектерү.
-Диалогик сөйләмдә еш очрый торган сүз җөмләләр белән таныштыру.
-Тулы һәм ким җөмләләрне аера белергә гадәтләндерү.
-Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне сөйләмдә куллану күнекмәләрен системалаштыру.
-Татар һәм рус җөмләләрендә сүз тәртибенең үзенчәлекләрен аңлап, сөйләм оештыруга ирешү.

-Туры сөйләмне дөрес төзергә күнектерү; тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.
-Фразеологик берәмлекләрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә кулланууга ирешү.
-Актив үзләштерелгән сүзләрнең синонимнарын, антонимнарын кулланып, җөмләләр төзергә өйрәтү.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерүгә мөмкинлек бирелә:

- Классташларның укуы, билгеләр алуы, өй эшен эшләү, дәрестә катнашу, яхшы уку серләре , яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар турында сөйләргә.

-Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләргә. Яшьтәшләреңнең тышкы кыяфәтен, характер сыйфатларын әйтә белергә. Матур киенү серләре турында сөйләргә.

-Табигать төшенчәсе, бүгенге экологик проблемалар, табигатькә сак караш турында сөйләргә.

-Табигать байлыгы, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белергә.

-Татарстанның табигате турында мәгълүмат бирә белергә. Казан шәһәре, андагы яңа үзгәрешләр турында сөйли белергә. Казан шәһәрендәге спорт корылмалары, ял итү урыннары, тарихи истәлекләр турында әңгәмәгә керә белергә.

**9 нчы класс**

Туган тел дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:
- Татар һәм рус телләрендәге аерым грамматик категорияләрнең тәңгәл килү-килмәвен белергә.
- Иярчен хәл җөмләләрнең иярчен вакыт, иярчен урын, максат җөмлә, шарт җөмлә, сәбәп җөмлә, кире җөмләләре белән таныштыру һәм аларны сөйләмдә урынлы куллануга ирешә.
- Аралашу ситуацияләренә бәйле лексик берәмлекләрне, аларның синонимнарын, антонимнарын урынлы куллана белергә.
- Татар теленең фразеологик берәмлекләрен таный һәм сөйләмдә куллана белергә.
- Гади һәм кушма җөмләләрне аера белергә.
- Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белеп куллана белергә.
- Татар һәм рус телләре арасындагы тарихи, мәдәни бәйләнешләр турында белергә.
- Төрле чыганаклардан (фәнни-популяр текстлар, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б.) файдаланып, кирәкле мәгълүматны таба һәм башкаларга телдән яки язмача җиткерә алырга.
- Мәдәниара аралашу ситуацияләрендә әңгәмә кора алырга.
- Татар әдәбияты әсәрләрен сәнгатьле укырга, сөйләргә, анализларга
- Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую һәм аларны тиешле интонация белән әйтергә.
- Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, сорау куя, аера белергә.
-Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдырырга.
- Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә кулланырга.

Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерүгә мөмкинлек бирелә:
-Татарстан турында гомуми белешмә бирә белергә: Татарстан Республикасының мәйданы, табигате, шәһәрләре, анда яшәүче милләтләре, Татарстан дәүләтенең символлары, аларның

авторлары турында сөйли белергә. Татарстан промышленносте продукцияләре турында әңгәмәгә керә белергә.
-Татар музыка сәнгате вәкилләре: Александр Ключарев, София Гобәйдуллина, Салих Сәйдәшев турында әңгәмә кора белергә. Татар театр сәнгате барлыкка килү турында белешмә бирә белергә. Татарстанда чыга торган газета-журналлары турында белешмә бирә белергә
-Төрле һөнәр ияләренең хезмәте, хезмәт базарындагы ихтыяҗы булган һөнәрләр турында әңгәмә кора белү. Яшүсмерләрнең эшкә урнаша алу вакыты, рөхсәт ителгән хезмәт төрләре турында сөйләшү. Уңышлы һөнәр сайлау шартлары турында әңгәмә кора белү. Гаилә әгъзаларының һөнәрләре, төрле һөнәрләргәгә хас сыйфатлар турында фикер алышу. Үзеңә ошаган профессияне яклый белү. Үзең яшәгән төбәктәге колледжлар, техникумнар, аларда әзерләнә торган һөнәрләр, уку үзенчәлекләре турында белешмә бирә белергә.
-Сәламәт яшәү кагыйдәләре, сәламәтлекне саклау өчен кирәк булган чаралар, спорт белән шөгыльләнергә кирәклеге турында сөйләшергә.
- “Зарарлы гадәтләрдән тыш яшәү – заманча яшәүме?” проблемасы буенча әңгәмә кора белергә. Кәрәзле телефон, плеерларны куллану, компьютер уеннары, аларга бәйлелек турында сөйләшергә.
-9нчы Май – Җиңү көне турында сөйли белергә. Татарстан уллары һәм кызлары – Советлар Союзы геройлары: Муса Җәлил, җәлилчеләр, Мәгубә Сыртланова, Газинур Гафиятуллин турында әңгәмә кора белергә. Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар, аларга хөрмәт күрсәтү турында сөйләшергә.

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

## **5 нче сыйныф** (70 сәгать)

1. **Без мәктәптә**

“Яңа уку елы котлы булсын!” темасы буенча эш. Дәресләр расписаниесе, дәресләр әзерләү, өй эше эшләү, билгеләр алу турында сөйләшү.

Исәнләшү кагыйдәләре.Син алмашлыгының юнәлеш һәм төшем килешләрендә кулланылышы. “Мәктәп” темасына караган лексик-грамматик материал. Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, санын, кирәклеген хәбәр итү (сорау), үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкъдим итү.

Исемнәрнең төшем һәм юнәлеш килешләрендә төрләнүе. “Мәктәптә Белем бәйрәме” текстындагы лексик-грамматик материал. Беренче сентябрь - Белем бәйрәме турында сөйләү. “Мәктәптә белем бәйрәме” тексты буенча диалогик-монологик сөйләм. Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең сөйләмдә кулланылышы. Исемнәрнең күплек санда тартым белән төрләнеше. Боерык фигыль турында төшенчә. Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Үтенеч белдерү формалары. Исем ясалышы. “Китап” шигырендә лексик-грамматик материал. Өйрәнелгән, актив куллануда булган сүзләрне дөрес язу. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта зат – сан белән төрләнеше. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасында зат – сан белән төрләнеше. Сан. Сан төркемчәләре (микъдар, тәртип, җыю саннары). “Сан+исем” төзелмәсе. “Без диктант язабыз” текстында лексик-грамматик материал. Теркәгечнең төркемчәләре.

**2. Мин – өйдә булышчы**

“Иртәнге режим” темасы буенча лексик-грамматик материал. Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйләү. Сәгать ничә? Сәгать ничәдә? Сораулары. Вакытны сорау, әйтү. “Малай нишли?” төзелмәсе. Өйдә эшләгән эшләрне әйтү, сорау, кушу. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Сүзлек диктанты. “Илнур белән Рәсим” текстында

лексик-грамматик материал. Кереш сүзләр. Кереш сүзләрнең сөйләмдә кулланылышы. Инфинитив . Инфинитив + ярый, кирәк төзелмәсе. Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (кирәк, кирәкми, ярый, ярамый) белән сөйләмдә куллану. Мактау формалары. Өйдәге эшләрне эшләргә киңәш бирү, яхшы эшләр өчен мактау. Фигыль төркемчәләре . “Рәсим” текстында лексик-грамматик материал .“Рәсим” тексты буенча диалогик-монологик сөйләм. Чөнки теркәгече. Рәсимгә бәя бирү. Җөмлә калыплары (Кем? Кемгә? Нишләргә? Нишлим? формасы). Өчен бәйлегеЮ. Ермалаевның “Ике пирожный” хикәясендәге лексик-грамматик материал. Ю. Ермалаевның “Ике пирожный” хикәясе өстендә эш. Ю. Ермалаевның “Ике пирожный” хикәясе буенча диалогик-монологик сөйләм. Кереш сүзләр. Кереш сүзләрне кулланып, образларга бәя бирү. Өйдәге хезмәттә катнашуга карап, кешеләргә бәя бирү. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы. “Тавык,Тычкан һәм Көртлек” әкиятендәге лексик-грамматик материал. Тезмә фигыль (алып бара, алып кайта конструкциясе). “Тавык,Тычкан һәм Көртлек” әкияте өстендә эш. “Тавык,Тычкан һәм Көртлек” әкияте буенча диалогик-монологик сөйләм. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.

**3. Дуслар белән күңелле**

“Минем дусларым” темасы буенча лексик-грамматик материал. Дустыңның барлыгын, кемнәр белән дус икәнеңне, аларның нинди булуын әйтү. Кайда, кайчан дуслашкан, дусның нинди булуын, бергә нишләгәнне сөйләү. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы. “Язгы каникул” текстында лексик-грамматик материал. “Язгы каникул” хикәясе өстендә эш. Боеру, үтенеч белдерү формалары. БСҮ ”Телефоннан сөйләшү этикеты”. Дусларны телефоннан уйнарга чакыру, туган көнгә итагатьле чакыру. Исем+исем сүзтезмәсе. Мин нәрсә яратам? Төзелмәсе. Татар халык ашларын, нәрсәләр ярату, яратмауны әйтә белү. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. “Без туган көнгә әзерләнәбез” хикәясе буенча диалогик-монологик сөйләм. “Гүзәл Ләйсәннәрдә” хикәясендәге лексик-грамматик материал.

“Без табын әзерлибез” темасындагы лексик-грамматик материал. Дуслар белән туган көнгә әзерләнү, кибеттән ризыклар алу, кибетче белән сөйләшү. Табын әзерләү турында сөйләшү. Туган көнгә чакыру формалары. “Туган көндә” темасы буенча диалогик-монологик сөйләм. “Табын янында” хикәясендә лексик-грамматик материал. Бәйлек сүзләрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә кулланылышы.

“Табын янында” хикәясе буенча диалогик-монологик сөйләм. Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сөйләү.

**4. Дүрт аяклы дусларыбыз**

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. “Дүрт аяклы дусларыбыз, аларның гадәтләре” темасы буенча диалогик сөйләм. Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйләшү. “Минем дүрт аяклы дустым” темасында лексик материал. Мин, син зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. “Акыллы Карабай” хикәясендә лексик-грамматик материал

“Дүрт аяклы дустым” циклын гомумиләштереп кабатлау. Этләр турында кызыклы мәгълүмат әйтү.

**5. Без спорт яратабыз**

“Тән әгъзалары” темасындагы лексик - грамматик материал. Тән әгъзаларының исемнәрен әйтү. Кайсы җирең авырта? соравы. Нәрсә авыртуын, авыртмавын табибка әйтү, сорау. Балалар нишлиләр? төзелмәсе. БСҮ “Мин яраткан спорт төре”. Спорт төрләрен аеру,

үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны, нинди спорт түгәрәгенә йөргәнеңне, физкультура дәресендә нәрсә эшләгәнеңне әйтү.
“Сәламәт булыйк” шигырендә лексик-грамматик материал.

## **6нчы сыйныф** (70 сәгать)

1. **Яңа уку елы башлана**

Котлау, мактау формалары. «Без мәктәпкә әзерләнәбез». Уку-язу әсбапларының исемнәре. «*Инфинитив+ ярыйммы (мөмкинме)* » төзелмәсе. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше, тартым кушымчалары. Тартымлы исемнәрнең сөйләмдә кулланышы. Транскрипция билгеләре. Без китаплар укыйбыз. Исемнәргә кушымчаларның ялгану тәртибе. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше, килеш кушымчалары, калын һәм нечкә сүзләрнең төрләнеше. Сорау алмашлыклары. Китап басу тарихына караган лексика. Татар китабы туу тарихы. Исем ясагыч кушымчалар. Татар телендә сүзлекләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. К.Насыйри - бөек галим. ... *булып эшли* төзелмәсе. Бәйлекләрнең сөйләмдә кулланылышы. Без китапханәдә. Мәктәп (шәһәр) китапханәсенә экскурсия, формуляр тутыру, китап алу. Китап укуның файдасы. Минем яраткан китабым. Иялек килеше, сораулары, кушымчалары, иялек килешенең сөйләмдә кулланылышы. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы, кушымчалары. Көндәлекне тутыру кагыйдәләре. Укучыга көндәлек ни өчен кирәк? Үз көндәлегең, көндәлектәге билгеләр турында сөйләү. Уку-язу әсбапларын тәртипле тоту киңәшләре. Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.

2. **Без – булышчылар**

Гаиләдә эшләнә торган эш төрләре. *3 нче зат берлек сан хәзерге заман х.ф. + беләм* төзелмәсе. *Боерык фигыль + әле* төзелмәсе. Шарт фигыль. Шарт фигыльнең юклык формасы. Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, сөйләмдә кулланылышы. Сыйфат дәрәҗәләре, предметларда дәрәҗә билгеләре. Өй хезмәте турында язма монологик сөйләм төзү (сочинение). Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. «Әхмәт нигә елады?» текстында лексик-грамматик материал. Кереш сүзләрнең сөйләмдә кулланылышы. Образга бәя бирү. *Эшли ала* төзелмәсе. Сорау җөмләләр. Шарт фигыльле җөмләләрдә сүз тәртибе. Супермалай нәрсәләр эшли ала? Теләк белдерү формасы: *инфинитив + телим* төзелмәсе. Мин – супермалай (суперкыз) - яңа хикәя төзү. Бәйлек сүзләр, бәйлек сүзләрнең җөмләдәге урыны. *Малайларның берсе* төзелмәсе. «Уллар» хикәясе.

3. **Дуслар белән күңелле**

Исемнәргә тартым һәм килеш кушымчаларының ялгану тәртибе. «Минем чын дустым» темасы буенча лексика. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Дуслар дискотекада. Үтенеч һәм рөхсәт сорау формалары: *барыйм инде, барыйм әле* төзелмәләре. Теләк белдерү формасы: *эчәсе килә төзелмәсе.* Билгеле киләчәк заман хикәя фигыль. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Рөхсәт сорау формалары. Рөхсәт сорау - кирәкле эш. «Зәңгәр яфраклар» хикәясендәге лексик-грамматик материал. Катя чын дусмы? Характер сыйфатларын ачучы сыйфатлар. *Чөнки, шуңа күрә* теркәгечләрен сөйләмдә куллану. Хикәя фигыльнең заман формаларын кабатлау. *Ошый, ошамый* сүзләре. Антонимнар, синонимнар. «Туган көндә» хикәясе. Туган көн бәйрәменә чакыру, өстәл әзерләү турында сөйләү. Ашарга пешерү тәртибе, төрле рецептлар. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. *Өйдә юк, өйдә түгел* төзелмәләре.

4. **Туган җирем – Татарстан**

Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. *Туган илем, туган җирем* төшенчәләре. Россиядәге, Татарстандагы диңгезләрне, елгаларны, шәһәрләрне атау. Татарстанның табигате. Татарстан Республикасының дәүләт символлары. «Англиядән килгән кунаклар»тексты буенча лексик-грамматик материал. Урын, вакыт, охшату-чагыштыру рәвешләре. Рәвеш төркемчәләрен сөйләмдә куллану. Үткән заман сыйфат фигыльләр. «Татарстанда яшәүче милләтләр» темасы буенча ЛГМ. Татарстанда яшәүче милләтләр,

аларның туган теле. «Татарстан – туган җирем» темасы буенча ЛГМ. Татарстанның климаты, анда яшәгән хайваннар, үскән үсемлекләр.Ия белән хәбәр арасында сызык. *Чөнки, шуңа күрә* теркәгечләрен сөйләмдә куллану. *Аркылы* бәйлеге. *Идел Чулманнан зуррак* төзелмәсе. *Казаннан Яр Чаллыга* кадәр төзелмәсе. Исем сүзтезмәләр. Казан шәһәре турында мәгълүмат. Г. Камал театры. Без театрга барабыз. Татарстанның танылган сәнгать вәкилләре.

**5. Табигать белән бергә**

Нәрсә ул табигать? Безнең әйләнә-тирәбез. Кешеләрнең урманга салган зыяны. Табигатьне саклау турында киңәшләр. *Инфинитив + кирәк* төзелмәсе. Боерык фигыльнең 3нче зат берлек һәм күплек сан формалары. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, сөйләмдә кулланылышы. Бездә яшәүче кошлар. Колибри – иң кечкенә кош. Кошлар, хайваннар тормышыннан кызыклы мәгълүматлар. «Кыргый хайваннар дөньясы» темасы буенча ЛГМ. Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре, тугрылыклыклары, аларны саклау, карау. Ачыклау максатыннан чыгып, төрле сорау алмашлыклары, кисәкчәләр кулланып, сорау җөмләләр оештыру.

**6. Сәламәт тәндә – сәламәт акыл**

Спорт төрләре. *Инфинитив + яратам (телим*) төзелмәсе. -*чы, -че* исем ясагыч кушымчалары. Нинди спорт төрләре белән шөгыльләнү турында сөйләшү. Олимпия уеннары, Олимпия уеннарындагы спорт төрләре, олимпия уты, олимпия флагы. Шарт фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. *Шуңа күрә, чөнки* теркәгечләрен кулланып, сәбәп белдерү. Тән әгъзалары. Табибта. Авыручыга киңәшләр бирү. Авыруның сәбәпләре, кайсы җирең авыртуы турында сөйләү. *Инфинитив(барлыкта һәм юклыкта) + кирәк (ярамый*) төзелмәсе. Сәламәт булу өчен, нинди кагыйдәләр үтәргә кирәк?

**7. Светофор – минем дустым**

Юлда сак булу. Юл йөрү кагыйдәләре. Юл йөрү кагыйдәләрен сакларга киңәш бирү

## **7нче сыйныф** (70 сәгать)

**1. Белем һәм тормыш.**

«Яңа уку елы» темасы буенча лексик-грамматик материал. Сыйфатлар ясалышы. Яңа уку елындагы яңалыклар, җәйге ялны ничек уздыру, классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләшү. Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыль. Хәл фигыль, хәл фигыльнең 4 төре, аларны сөйләмдә куллану. «Мәктәптә беренче көн», «Без киңәшләр бирәбез» темалары буенча сөйләм үрнәкләре. Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Китапханәдә формуляр тутыру, кирәкле китапның исеме, авторы. Рәвеш төркемчәләре. Сәбәп белдерү формасы. Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. «Көндәлек – документ, көндәлек - синең көзгең» темасы буенча лексик-грамматик материал. Яхшы уку серләре, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар. «*Инфинитив+кирәк*» төзелмәсе.

**2. Без бергә ял итәбез.**

Сыйфат фигыльнең заман формалары, сөйләмдә кулланылышы. Җөмләнең баш кисәкләре. «Буш вакыт» темасына караган лексик-грамматик материал. Ия белән хәбәр арасындагы сызык. Буш вакыт. Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен тотышы турында сөйләшү, бәя бирү. Теркәгечләр. «Минем буш вакытым» темасына сөйләшү. Исем фигыльнең барлык, юклык формасы. Кереш сүзләр. «Ялгыш адым» шигырендәге лексик-грамматик материал. «Нәрсә ул егетлек?» проблемасы буенча лексик грамматик материал. Бездәге үрнәк сыйфатлар. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. «Безнең йортның подъезды» темасына сөйләшү.

**3. Өлкәннәр һәм кечкенәләр.**

Җөмләнең иярчен кисәкләре – тәмамлык, хәл. Тәрбиялелек сыйфатлары. «Без бер-беребезгә булышабыз», «Ярдәмләшеп яшәү күңелле» темасы буенча сөйләм үрнәкләре. Исем фигыльнең килешләр белән төрләнеше, сөйләмдә кулланылышы. «Ата-анага

хөрмәт» темасына караган лексик-грамматик материал. Кисәкчәләр. Аралашу әдәбе, «Тәрбияле булу заманчамы?» проблемасы буенча сөйләшү. Билгеләү алмашлыклары. Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте, кушкан эшкә җаваплы караш турында сөйләшү. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне, кайчан кайтасыңны әйтү, рөхсәт сорау формалары. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү турында сөйләү. Әти-әниләрне бәйрәм белән котлау үрнәкләре.

**4. Без Татарстанда яшибез.**

«Туган ягым - Татарстан» темасына караган лексик-грамматик материал. Татарстанның географик урыны, климаты, байлыклары. Татарстанның сәнәгате. «Без Татарстанда яшибез» темасы буенча сыйләшү. Теләк белдерү формалары, теләк фигыль. Максат белдерү формалары. Атаклы композитор Сара Садыйкова.

## 8нче сыйныф (70 сәгать)

### 1. Күп укыган – күп белер

«Мәктәп» темасы буенча лексика. Комплимент әйтү формалары. Уку әсбаплары. Хәзерге заман хикәя фигыль. Тартык һәм сузык авазларга беткән исемнәрнең тартым белән төрләнешен кабатлау. Сорау кисәкчәләре. Минем җәйге ялым.Р.Вәлиеваның«Мәктәбем» шигырендәге лексик-грамматик материал. Классташларның укуы, билгеләр алуы, өй эшен эшләү, дәрестә катнашу турында сөйләм үрнәкләре. Интернет аша үз белемеңне күтәрү. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хәл фигыль, аның ясалышы һәм сөйләмдә кулланылышы. «Өлгерәм әле» тексты буенча лексик-грамматик материал. «Өлгерәм әле» тексты героена киңәшләр бирү. Шарт фигыль турында төшенчә, ясалу ысуллары, зат-сан белән төрләнеше. Инфинитив. Инфинитивны сөйләмдә куллану. Яхшы уку кагыйдәләре, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар. Р. Вәлиеваның «Барый телевизор карый» шигырендә начар укуның сәбәпләре. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе тарихы.

### 2. Мин һәм минем яшьтәшләрем

Яшьтәшләрең белән аралашу. «Аралашу серләре» текстында лексик-грамматик материал. Яшьтәшләр белән аралашу кагыйдәләре. Яшьтәшләрнең тышкы кыяфәте һәм эчке сыйфатлары. Тышкы кыяфәтне һәм характерны белдерүче сыйфатлар. Шарт фигыльнең барлык һәм юклык формалары. *Инфинитив+модаль сүзләр* төзелмәсе. «Әдәп кагыйдәләре» текстындагы лексик-грамматик материал. Әдәп кагыйдәләрен үтәү кирәкме? Исем фигыль, аның килешләр белән төрләнеше. Психолог киңәшләре. М.Галиевның «Җиңәсем килде»әсәрендәге лексик-грамматик материал. Геройга характеристика бирү, аның уңай һәм тискәре сыйфатларын күрсәтү, ялганлашуга карата үз фикереңне әйтү. Сыйфат фигыль, аның заман формалары.«Ал кирәк, гөл кирәк» текстындагы лексик-грамматик материал. Сиңа нинди кызлар (егетләр) ошый? Алмашлыклар. Аларның төркемчәләре. Билгеләү алмашлыклары, аларның ясалышы һәм кулланылышы. «Минем төсем – яшел? Ә синеке?» текстында лексик-грамматик материал. Киемгә карата комплиментлар. Сиңа нинди кием килешә? Төсләр кәефкә ничек тәэсир итә? Матур киенү серләре. «Музыка дөньясында» тексты. Яраткан шөгыльләр: музыка, бию, рәсем ясау, уку h.б. Музыкаль бәйрәмнәр. Танышу өчен хатлар, хат язу үрнәкләре.

### 3. Табигать һәм кеше

Нәрсә ул табигать?Табигать төшенчәсе. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Ия белән хәбәр арасында сызык. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр. Табигать –безнең әйләнә-тирәбез. Табигатьне саклау оешмалары турында мәгълүмат. Теләк фигыль, аның барлыкта һәм юклыкта кулланылуы. Башка теләк белдерү формалары. Теркәгечләр, тезүче һәм ияртүче теркәгечләр. Теркәгечләрне җөмләдә куллану. «Урман» текстында

лексик-грамматик материал. Урман – кешенең якын дусты. Безнең як урманнары. Исемнәрнең ясалыш ысуллары. Парлы, кушма, тезмә, кыскартылма исемнәр. Сыйфат дәрәҗәләре. «И ямьле соң бу дөнья» текстында лексик-грамматик материал. Минем яраткан ел фасылым. Дару үләннәре. Табигать һәм кеше. Табигатьтәге кызыклы күренешләр. Бүгенге экологик проблемалар. Табигатькә сак караш.

**4. Туган җирем – Татарстан**

«Туган ягым – Татарстан» темасына караган лексик-грамматик материал.Татарстанның урнашкан урыны, климаты, мәйданы, табигый байлыклары.Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. «*Исем+исем*» сүзтезмәсе. Татарстанның табигате.«Казан» тексты. Татарстанның башкаласы Казан, аның бүгенге йөзе. Казанның истәлекле урыннары: Казан Кремле, Сөембикә манарасы, Татарстанның Милли музее, Бауман урамы, музейлар. Казанда яшәгән атаклы шәхесләр.Казан – спорт шәһәре. Казандагы спорт корылмалары. Казанда уздырылган спорт ярышлары. Казанда ял итү урыннары. Сөембикә манарасы, аның турында легендалар, интернет-экскурсия. Татарстанда яшәүче халыклар. Шәһәребездә Сабантуй бәйрәме, Сабантуйдагы уеннар, күңел ачу урыннары. Максат, теләк белдерү формаларын кабатлау. 8 нче сыйныф курсы материалын кабатлау.

## **9нчы сыйныф** (68 сәгать)

**Без Татарстанда яшибез**

Дәреслек белән эш кагыйдәләре. Без Татарстанда яшибез. Татарстанның географик урыны, шәһәрләре, елгалары. Татарстанда яши торган халыклар. Татарстанның табигате. Татарстанның табигый байлыклары. Татарстанның икътисади үсеше. Танылган сәнгать әһелләре. Александр Ключарёв – танылган татар композиторы. Танылган рәссам Харис Якупов. Харис Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя язу. Якташыбыз композитор София Гобәйдуллина. Татар театры. Татарстанда чыга торган газета-журналлар. Изафә бәйләнешен кабатлау. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Кушма җөмлә. Тезүче һәм ияртүче теркәгечләр Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләр. *Сыйфат+исем* сүзтезмәләрен кабатлау. Иярченле кушма җөмләләр. Аналитик һәм синтетик бәйләүче чаралар.

**Һөнәр сайлау**

Исем ясагыч кушымчалар. ... *булып эшли* төзелмәсен искә төшерү. Иярчен җөмлә төрләре. Иярчен ия җөмлә, бу төр җөмләдә бәйләүче чаралар. Яраткан һөнәр турында сөйләшү. Иярчен хәбәр җөмлә, аның аналитик төре генә булуы.. Һөнәр сайлау - җаваплы эш. Аналитик һәм синтетик иярчен аергыч җөмләләр, аларның бәйләүче чаралары. Кайсы һөнәрләргә ихтыяҗ зур? Иярчен тәмамлык җөмләнең аналитик һәм синтетик төрләре. Хәл турында кабатлау. Шарт фигыль. Р. Вәлиеваның «Гомәр һәм һөнәр» шигыре буенча тел күнегүләре. «Минем булачак һөнәрем»темасына хикәя язу. Иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә, аның аналитик һәм синтетик төрләре. Яшүсмерләргә рөхсәт ителгән хезмәт төрләре. Хикәя фигыль, аның хәзерге, үткән, киләчәк заман формаларын кабатлау. Укытучы һөнәре турында сөйләшү. Килешләр турында кабатлау. Тезүче һәм ияртүче теркәгечләр (кабатлау). Иярчен урын җөмләле кушма җөмлә, аның аналитик һәм синтетик төрләре. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәреннән өзек уку, табиб һөнәренә хас сыйфатлар. Иярчен максат җөмләле кушма җөмлә, аның аналитик һәм синтетик төрләре. Хезмәт кешесенә хөрмәт. *Соң* бәйлеге. Икмәккә сак караш.

**Сәламәтлек – зур байлык**

Инфинитив, инфинитивның барлык һәм юклык формасы. Сәламәт яшәү кагыйдәләре. Исем фигыльнең килешләр белән төрләнеше. Тәмәке тартуның зарары. Исерткеч эчемлекләрнең зарары. *Барасым килә, эшлисем килә ( килми)* теләк белдерү формалары. Наркотик – ак үлем. Гаджетларга бәйлелек. «Сәламәт яшәү рәвеше» темасына проект эше.

**Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый**

Беренче Советлар Союзы Герое Никита Кайманов. Бөек Ватан сугышы турында өстәмә мәгълүмат туплау. Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Ш. Маннурның «Муса» романнынан өзек буенча лексик-грамматик материал. Андре Тиммерманс белән Муса Җәлил арасындагы дуслык мөнәсәбәтләре. Кемнәр ул – җәлилчеләр? Тема буенча иҗади эш ( реферат, презентация, проект эше һ.б.). Очучы Мәгубә Сыртланова. Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин. Бөек Ватан сугышы турында рус язучыларының әсәрләре.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

### 5 нче сыйныф

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Дәресләр | Контроль эшләр |
| 1 | Без мәктәптә | 19 | 19 | |
| 2 | Мин – өйдә булышчы | 21 | 21 | |
| 3 | Дуслар белән күңелле | 15 | 14 | 1 |
| 4 | Дүрт аяклы дусларыбыз | 7 | 7 | |
| 5 | Без спорт яратабыз | 8 | 7 | 1 |
| | Барлыгы | 70 | 68 | 2 |

### 6 нчы сыйныф

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Дәресләр | Контроль эшләр |
| 1. | Яңа уку елы башлана | 22 | 22 | |
| 2. | Без – булышчылар | 8 | 7 | 1 |
| 3. | Дуслар белән күңелле | 12 | 12 | |
| 4. | Туган җирем – Татарстан | 13 | 13 | |
| 5. | Табигать белән бергә | 6 | 6 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Сәламәт тәндә – сәламәт акыл | 9 | 8 | 1 |
| | Барлыгы | 70 | 68 | 2 |

**7 нче сыйныф**

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Дәресләр | Контроль эшләр |
| 1. | Белем һәм тормыш | 21 | 21 | |
| 2. | Без бергә ял итәбез | 21 | 20 | 1 |
| 3. | Өлкәннәр һәм кечкенәләр | 18 | 18 | |
| 4. | Без Татарстанда яшибез | 10 | 9 | 1 |
| | Барлыгы | 70 | 68 | 2 |

**8 нче сыйныф**

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Дәресләр | Контроль эшләр |
| 1 | Күп укыган - күп белер. | 18 | 18 | |
| 2 | Мин һәм минем яшьтәшләрем. | 15 | 14 | 1 |
| 3 | Буш вакытымны мин ничек үткәрәм. | 7 | 7 | |
| 4 | Табигать һәм кеше | 4 | 4 | |
| 5 | Без Татарстанда яшибез | 9 | 9 | |
| 6 | Татарстанның күренекле әдипләре | 17 | 16 | 1 |
| | Барлыгы | 70 | 68 | 2 |

**9 нчы сыйныф**

| Бүлекләр исеме | Сәгать саны | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Дәресләр | Контроль эш |
| Без Татарстанда яшибез | 18 | 18 | |
| Һөнәр сайлау | 25 | 24 | **1** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сәламәтлек – зур байлык | 12 | 12 | |
| Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый | 13 | 12 | **1** |
| БАРЛЫГЫ | 68 | 66 | 2 |